Муниципаль автономлы мӳдӳният учреждениесы
«Чакмагыш ïзӳк билӳмӳ-ара китапханӳсе»

Халкыбыз гәүһәрләре



# Халык язмышы-эдип язмышы

(1884-1942)

## Шәриф Камалга 130 яшь



Татар әдәбияты классикасының күренекл
Шәриф Камал (Шәриф Камалетдин улы Байгилд
февралендә элекке Пенза губернасы Инсар өязе
Республикасының Рузаевка районы) Пешлә (Тат
мулла гаиләсендә туа. Башлангыч белемне үз ав
1900-нчы елларда күрше Ләбеҗә авылындагы м
холыклы, иске карашлы этисенә матди бәйлеле
Камал шәкерт чагыннан ук үз көнен үзе күрә башлый. Җәйләрен Мәскәү-Казан тимер юлында төрле яллы эшләрдә эшләп йөри, 1901 елда исә, бер сәүдәгәргә ялланып, Рига шәһәренә китә. Анда берникадәр вакыт торгач, төплерәк белем алу нияте белән башта Төркиягә, аннары Мисырга барып чыга. Ләкин, матди як начар булу сәбәпле, ике елдан кире Россиягә әйләнеп кайта һәм 1903-1904 елларда Украинадагы күмер шахталарында, Каспий диңгезе буендагы балык промыселларында эшли.

1905-нче елгы революцияне Ш. Камал Петербургта татар мәдрәсәләренең берсендә мөгаллим булып каршылый. Бер үк вакытта ул «Нур» исемле беренче татар газетасы редакциясенә корректорлык хезмәтенә урнаша һәм шушы газета битләрендә үзенең тәүге әдәби тәҗрибәләрен — мәгърифәтчелек рухында язылган шигырьләрен һәм публицистик мәкальләрен бастыра. 1906-нчы елда шул газета матбагасында яшь авторның «Сада» («Аваз») исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.



Революция җиңелеп, илдә реакция чоры башлангач, Ш. Камал туган авылы Пешләгә кайта һәм 1910-нчы елга кадәр шундагы мәдрәсәдә балалар укыта. Ул үзе дә белемен күтәрү өчен даими эшли, рус әдәбиятын, аерым алганда, М.Горький, А.Чехов иҗатларын тырышып өйрәнә. Шушы чорда ул проза жанрындагы беренче әсәрен — «Уяну» исемле хикәясен (1909) яза һәм аны Оренбургта Рәмиевләр химаясендә чыга торган «Шура» журналына җибәрә. Озакламый хикәя журналда басылып та чыга.

1910 елда Ш.Камал гаиләсе белән Оренбургка күчеп килә һәм шул елдан башлап Октябрь инкыйлабына чаклы «Шура» журналы һәм «Вакыт» газетасы нәшриятында әүвәл хисапчы, ә соңга таба редакциянең әдәби хезмәткәре булып эшли.

Шәриф Камалның Оренбург чоры зур иҗади активлык белән характерлы. Алты-җиде ел эчендә ул утыздан артык хикәя, дистәләрчә фельетон һәм мәкалә, атаклы «Акчарлаклар» повестен (1914) һәм «Хаҗи әфенде өйләнә» исемле сатирик комедиясен (1915) иҗат итә. Шул чор татар җәмгыятенең төрле якларын, бигрәк тә хезмәт кешеләренең — сезонлы эшчелер, балыкчылар, шахтерлар, интеллигенция вәкилләре тормышын реалистик картиналарда һәм үзенчәлекле образларда тасвирлаган «Акчарлаклар» повесте һәм хикәяләре белән Ш.Камал XX гасыр башы татар әдәбиятының тематик колачын һәм сәнгатьчә сүрәтләү алымнарын сизелерлек киңәйтеп җибәрә. Аның татар әдәбиятында кыска хикәя жанрын үстерүгә керткән өлеше аеруча зур. Кеше образларын психологик планда гәүдәләндерү, эмоциональ-лирик моң, аз сүз белән бирелгән тирән мәгънә, композицион җыйнаклык һәм тыгызлык — әдипнең хикәяләренә әнә шул сыйфатлар хас.





Шәриф Камалның музей-квартирасы

**Адрес:**
Чакмагыш авылы,
Кооператив урамы, 44 А
Тел.: 3-13-46

Библиографик күрсәткеч
Төзүчесе: Сафиуллина Ф.Г.

Чакмагыш -2014



1918-нче ел башында Рәмиевләрнең матбагалары совет хак… яләнеп «Шура» журналы һәм «В… ч, Ш.Камал, берникадәр вакыт эшсез йө… үвәл — Оренбургта чыга башлаган «Э… истик газетада, аннары Төркестан фр… үлеге органы «Кызыл Йолдыз» газетасында эшли һәм язышa. 191-нчы елның көзендә аны Коммунистлар партиясенә әгъза итеп алалар.

1920-1921-нче елларда Ш.Камал Оренбургтан ерак түгел урнашкан Чебенле авылында коммуна оештыруга катнаша. Соңрак Оренбургка яңадан кайтып, балалар йорты мөдире, укытучылар профсоюзының губерна бүлеге идарәсендә кассир һәм тәэминат бүлеге мөдире була, укытучылар әзерли торган курсларда дәресләр алып бара, 1924-1925-нче елларда исә «Юл» (соңрак — «Сабан») исемле газетада башта редколлегия әгъзасы, аннары җаваплы мөхәррир хезмәтләрен үти.

1925 елның көзендә Ш.Камал ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты карамагына җибәрелә һәм «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасы редакциясенең партия бүлеге мөдире итеп билгеләнә. Соңыннан ул Татарстан мәдәнияте йортында гыйльми секретарь (1928), Главлит хезмәткәре (1929-1932), Татар дәүләт академия театрының әдәбият бүлеге мөдире (1933-1935) вазифаларын башкара. Гомеренең соңгы елларында ул профессионал язучы хезмәтендә.



Совет хакимияте чорында Шәриф Камал зур күләмле проза әсәрләре һәм драмалары белән таныла. 1927-нче елда әдипнең эшче һәм солдатларны, җәмгыятьне яңабаштан кору юлындагы хәрәкәтен эпик планда чагылдыруны максат итеп куйган «Таң атканда» исемле романы басылып чыга. «Акчарлаклар» повестеның дәвамы рәвешендә язылган бу әсәрендә автор элек бәхет эзләп йөргән үз геройларының яңа шартларда зур көрәшләр аша чын дөреслеккә омтылу юлындагы хыялларын сүрәтли.

1928-1934-нче еллар арасында Шәриф Камал драматургия жанрына игьтибарын юнәлтә. Бу чорда аның бер-бер артлы «Ут» (1928), «Козгыннар оясында» (1929), «Таулар» (1931), «Томан арты» («Габбас Галин», 1934) исемле әсәрләре языла һәм Татар дәүләт академия театрында зур уныш белән бара. Бу әсәрләр татар сәхнәсенә эшче образларын, хезмәт ияләренең үз арасыннан үсеп чыккан яңа совет интеллигенциясе вәкилләрен алып менүе һәм шул чор тормышын кискен конфликтларда, сәнгатьчә чагылдыруы белән әһәмиятле.

Утызынчы елларның ахырларында, драма әсәрләре язу белән бергә, әдип үзенең совет чоры иҗатындагы күренекле әсәрләреннән берсе булган «Матур туганда» исемле романын бирелеп эшли. Берничә томнан торачак зур эпопеяның беренче китабы итеп уйланылган бу роман 1937-нче елда аерым китап булып басылып чыга һәм шундук татар прозасының зур казанышы итеп бәяләнә. Әсәрдә Октябрь инкыйлабы нәтиҗәсендә яңа тормыш кору хыялы белән бәйле киеренке вакыйгалар турында сөйләнә һәм шул дәвернең реаль картиналары фонында дистәләрчә тормышчан типлар, характерлар бирелә. Соңыннан (1940 елда) автор романның сәхнәләштерелгән вариантын да эшли.



1939-1940-нчы елларда «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында әдипнең «Ныклы адымнар» исемле яңа романы («Матур туганда»ның дәвамы) басыла башлый. Ләкин әсәр тәмамланмый кала. Моңа сугыш комачаулый. Ватан сугышы башлану белән, Ш.Камал үз каләмен фашист илбасарларына каршы юнәлтә: матбугат битләрендә публицистик мәкаләләр белән чыгышлар ясый, «Март» исемле хикәясен бастыра һәм «Сафура» исемле пьеса яза башлый.

Шәриф Камал — үзенең бөтен иҗади таланты һәм иҗтимагый эшчәнлеге белән татар халкының рухи үсешенә армый-талмый хезмәт иткән язучыларның берсе. Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен ул 1940-нчы елда Ленин ордены белән бүләкләнә, аңа шулай ук «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә, 1939-нчы елда Казан хезмәт ияләре аны шәһәр Советына депутат итеп сайлыйлар.

Әдип 1942 елның 22 декабрендә кинәт вафат була.

Ш. Камал — 1934 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

## ТӨП БАСМА КИТАПЛАРЫ

Шәриф Камал әсәрләре: 1 кисәк /кереш сүз авт. Г.Толымбай. — Казан: Яңалиф, 1929, — 164 б.
Сайланма әсәрләр. — Казан: Татгосиздат, 1938. — 685 б.
Әсәрләр: 2 томда. — Казан: Татгосиздат, 1941-1950.
1 т.: хикәяләр, повесть, роман /кереш сүз авт. Г.Кашшаф. — 1941. — 420 б.
2 т.: пьесалар /кереш суз авт. Г.Кашшаф. — 1950. — 343 б.
Әсәрләр: 4 томда. — Казан: Татгосиздат, 1952-1956.
1 т.: хикәяләр, повесть, роман. — 1952. — 335 б.
2 т.: пьесалар. — 1952. — 342 б.
3 т.: роман. — 1951. — 312 б.



4 т.: хикәяләр, фельетоннар, очерклар, роман, пьеса, тәнкыйть һәм публицистика /кереш суз авт. М.Максуд. — 1956. — 226 б.
Сайланма әсәрләр: 3 томда. — Казан: Татар кит. нәшр., 1974-1976.
1 т.: хикәяләр, повесть, роман. — 1974. — 381 б.
2 т.: роман. — 1974. — 373 б.
3 т.: пьесалар, роман, мәкаләләр. — 1976. — 415 б.
Бәхет эзләгәндә: хикәяләр, повесть. — Казан: Татар, кит. нашр., 1989. — 160 б.
Сайланма әсәрләр /кереш сүз авт. Ф.Бәшир. — Казан: Татар, кит. нашр., 2004. — 446 б.
Сайланма әсәрләр. — Казан: Хэтер, 2006. — 495 б.

## АНЫҢ ТУРЫНДА

Кашшаф, Г. Шариф Камал. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1940. — 141 б.
Гайнуллин, М., Вәзиева, Җ. Ш. Камал: Тормышы һәм иҗаты /Гайнуллин М., Вәзиева, Җ. Татар әдәбияты. XX йөз. 2 нче кисәк. - Казан: Тат. кит. нәшр., 1954. — 203-232 б.
Нигьмәти, Г. Ш. Камал — драматург /Нигьмәти Г. С... Казан: Тат. кит. нвәшр., 1958. — 147-153 б.
Хисмәтуллин, Г. Шәриф Камал /Татар совет әд... Казан: Тат. кит. нәшр., 1960. — 403-439 б.
Нуруллин, И. Ш.Камал иҗаты: Мәкаләләр. — ... нәшр., 1963. — 70 б.
Нигьмәтуллин, Ә. Шәэриф Камал. — Казан: Тат. кит... 2 б.
Нигьмәтуллин, Ә. Шәриф Камал /Татар әдәбияты тарихы 6 томда. — 4 т. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1989. — 401-415 б.
Ханзафаров, Н. Татарская комедия. — Казань: Фән. — 1996.- С. 266.



Библиографик күрсәткеч
Шәриф Камалның тормыш юлы һәм иҗаты белән кызыксынган китап укучыларга тәкъдим ителә.

